МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.12.2017ел Казан ш. № 452

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы структурасында үзгәрешләр булуга бәйле рәвештә һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы указын, Татарстан Республикасы Президентының «Аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъвалык итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указын үтәү максатында боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә:

2.1. Әлеге боерык белән Министрлыкның Вазыйфалар исемлегенә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен таныштырырга.

2.2. Эштән куылганда Министрлыкның Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезләмәләрен аңлатырга.

2.3. Әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга.

2.4. Әлеге боерык күчермәсен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган көненнән соң өч көнлек чорда, Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә, Татарстан Республикасы Президенты каршында Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына җибәрергә.

3. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек бүлегенә (Сәгыйтов И.С.) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтының «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 12 декабрендәге 397 номерлы боерыгының көчен югалтуын танырга.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2017 елның «__»__________
№___ боерыгы белән
расланды

## Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры;

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы икътисад министры ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

эшләр белән идарә итүче;

Административ реформа мәсьәләләре идарәсе башлыгы;

Территориаль үсеш идарәсе башлыгы;

Инвестицион һәм инновацион эшчәнлек идарәсе башлыгы;

Оештыру идарәсе башлыгы;

юридик бүлек башлыгы;

финанс исәбенә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы;

дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы;

икътисад тармакларын һәм социаль өлкәне үстерү бүлеге башлыгы;

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры урынбасары;

мобилизацияле әзерлек һәм гражданлык оборонасы секторы җитәкчесе;

җайга салу йогынтысын бәяләү һәм икътисад өчен кадрлар әзерләү секторы җитәкчесе;

юридик бүлек башлыгы урынбасары;

финанс исәбенә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары;

икътисад тармакларын һәм социаль өлкәне үстерү бүлеге башлыгы урынбасары.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

инвестицион эшчәнлек бүлеге башлыгы;

икътисадый анализ һәм проектлар белән идарә итү бүлеге башлыгы;

инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы;

муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге башлыгы;

максатчан программалар бүлеге башлыгы;

лицензияләү бүлеге башлыгы;

конкуренция һәм эшкуарлык үсешен анализлау бүлеге башлыгы;

кече һәм урта эшкуарлыкны инфраструктур үстерү бүлеге башлыгы;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына теләктәшлек күрсәтү институтларын үстерү бүлеге башлыгы;

мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы;

административ-хуҗалык бүлеге башлыгы;

инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы урынбасары;

муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге башлыгы урынбасары;

максатчан программалар бүлеге башлыгы урынбасары;

конкуренция һәм эшкуарлык үсешен анализлау бүлеге башлыгы урынбасары;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына теләктәшлек күрсәтү институтларын үстерү бүлеге башлыгы урынбасары;

икътисадый анализ һәм проектлар белән идарә итү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

икътисадый анализ һәм проектлар белән идарә итү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

конкуренция һәм эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

конкуренция һәм эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

кече һәм урта эшкуарлыкны инфраструктур үстерү бүлегенең әйдәр баручы киңәшчесе;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына теләктәшлек күрсәтү институтларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

кече һәм урта эшкуарлыкны инфраструктур үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече;

конкуренция һәм эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең әйдәп баручы белгече;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына теләктәшлек күрсәтү институтларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы белгече.

7. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына теләктәшлек күрсәтү институтларын үстерү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече.